РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.01.2021 № 82-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 5 мартындагы 360-п номерлы карары белән расланган спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибенә һәм нормаларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә, спортны үстерүгә ярдәм итү, югары спорт нәтиҗәләренә ирешү өчен спортчыларның эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибен һәм нормаларын раслау турында” 2020 елның 5 мартындагы 360-п номерлы карары белән расланган, спорт чараларында катнашучыларны һәм хезмәт күрсәтүче персоналны матди яктан тәэмин итүгә акчалар тоту тәртибенә һәм нормаларына, 6 бүлек таблицасына түбәндәге эчтәлекле 1.1. пунктын өстәп, үзгәреш кертергә:

“

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| .1 | “Саба-Чаңгы” чаңгы ярышлары буенча төнге ярышларда абсолют категориядә призлы урыннар алган спортчылар | I | | 10000гә кадәр |
| | | II | | 9000гә кадәр |
| | | III | | 8000гә кадәр |

”.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р.Ишниязов